КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 июль г.Казань № 726

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт йөкләмәсе (заказ) урнаштырыла торган дәүләт хезмәтләрен, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә күчү чаралары планын раслау турында» 2021 ел, 13 апрель, 242 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт йөкләмәсе (заказ) урнаштырыла торган дәүләт хезмәтләрен, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә күчү чаралары планын раслау турында» 2021 ел, 13 апрель, 242 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 19 июль, 589 нчы, 2022 ел, 16 февраль, 134 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның $7^4$ статьясында билгеләнгән таләпләрне техник яктан гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә»;

әлеге карар белән расланган дәүләт йөкләмәсе (заказ) урнаштырылган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрне, дәүләт хезмәтләрен электрон рәвештә күрсәтүгә күчү чаралары планын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карарга теркәлгән кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин